Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2:256)

# Ислам нуры

№ 4 (656) 26 февраль, 2018 ел (1439, Җөмәдел–ахир) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга 12+



*2018 ел – Шиһабетдин Мәрҗани елы*

## И Казан, нурлы Казан...



... Россия 961(1552) ел ахырында татарларны җиңеп, Казан шәһәрен һәм аның тирә-юнен яулап алганда кальга эчендә сигез манаралы бер җәмигъ мәчет, «Таҗик ермагы» дип йөртелгән урында тагын бер мәчет һәм мәдрәсә була. Галимнәрдән, хөрмәткә лаек габбасилардан һәм бөек сәедләрдән күпмедер шәхесләр булып, аларның башында нәкыйбел-әшраф (бөекләрнең җитәкчесе) дип танылган мелла Шәрифкол исемле бер зат тора. Ул ислам ханнары һәм шәһәр халкы алдында ихтирамга һәм зур хөрмәткә лаек була.

«Росия князьләре Казан ханнарына илчеләр аша хатлар күндергәндә, мелла Шәрифколга да махсус хат һәм бүләкләр җибәрә иделәр»,– дип сөйлиләр. Ахырда, россиялеләр Казанга һөҗүм иткәндә, ул үзенең иярченнәрен җыеп мәдрәсәгә керә һәм мәдрәсә түбәсенә чыгып, россиялеләр белән бик каты сугыша. Руслар аны мәдрәсә түбәсеннән чәнчеп төшерәләр һәм ул шулай итеп шәһит була...

Шулай да Казан Россия составына кергәч, мөселманнарның дин һәм дөнья эшләренә комачаулык һәм кысынкылыклар булмый. Татарлар арасында туган дәгъва һәм низагларны, мәеттән калган малны бүлү һәм васыятьләрне үз меллалары һәм олылары җиренә җиткереп хәл кылалар. Теләгән җиргә һәм теләгән рәвештә мәчет, мәктәп һәм мәдрәсәләр бина кылганнар. Кемне ихтыяр итсәләр, әгәр ул риза булса, имам иткәннәр. Имамнарны кире кагуда да мәхәллә һәм авыл халкы мөстәкыйль булган. Балаларга исем бирү, өйләнү, мәетләрне күмүдә һәркем үз ихтыярында булып, моңа кем дә булса читтән катнашмаган, ягъни Россия дәүләте бу эшләргә һичнинди каршылык кылмаган.

Шуның өстенә, бистә халкы, ягъни шәһәрнең төп халкы булган мөселманнар үзләре әһле ислам телендә – «йомышлы мөселманнар», ә россиялеләр каршында «татар сәүдәгәрләре» исемендә танылып, һичнинди комачаулыксыз, тулы ирек белән һәртөрле сәүдә һәм алыш-биреш алып барырга хаклы булганнар. Бу хәл 1220 (1805) елга чаклы дәвам иткән.

Моннан соң «йомышлы мөселманнарның» бу хокуклары һәм сәүдәдә яшәп килгән тәртипләр бетерелгән. Сәүдәгәрләр дүрт дәрәҗәгә бүленеп, дүртенчесе «мещан» дәрәҗәсенә төшерелә. Беренче дәрәҗә сәүдәгәрләргә бөтен Россиядә, хәтта чит илләр белән дә сәүдә итү хокукы бирелә. Икенче дәрәҗәдәгеләрдән чит илләр белән сәүдә итү хокукы алынып, алар — Россиянең барлык өлкәләрендә, өченче дәрәҗәдәгеләр — кайбер өлкәләрдә генә, ә мещаннар исә фәкать үз шәһәрләрендә генә сәүдә һәм алыш-биреш итәргә хокуклы булып кала. Һәркайсы, дәрәҗәсенә күрә, хәзинәгә билгеле күләмдә салым түләү, мещаннардан башкаларның гаскәр хезмәтенә алынмау тәртибе кертелә.

Авыл халкының исә асыл затларыннан башкалары ике төркемгә бүленә һәм берсе — «казакъ», икенчесе «ясаклы» исеме белән атала. Ясаклылардан бары имана алынып, чирүгә бару хезмәтеннән азат ителәләр. «Казакъ» җәмәгатенә исә кирәк чакта чирүгә бару бурычы йөкләнә...

*“Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар” — “Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр”китабыннан.*

***Шиһабетдин Мәрҗани***

## Җиңүчеләр бүләк алды



Шушы көннәрдә “Без — татарлар” дип исемләнгән журналист эшләре конкурсы тәгәлләнде. Йомгаклау тантанасы Казанның Галиев мәчетендә узды, җиңүчеләргә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин бүләкләр тапшырды. Бәйгедә катнашу өчен телевидение, радио, интернет, матбугат әһелләре үзләренең иҗади хезмәтләрендә татар теленең дәрәҗәсен күтәрү, мәктәпләрдә татар телен өйрәнү, җәмәгатьчелектә дәүләт телләрен тигез күләмдә файдалану кебек мәсьәләләрне күтәреп чыгарга тиеш иделәр. Мөфти җитәкчелегендәге жюри әгъзалары игътибарына рус һәм татар телләрендәге 300 гә якын эш тәкъдим ителде, бәйгедә 79 журналист катнашты. Хәзрәт тел турындагы мөһим төшенчәләрне киң җәмәгатьчелеккә аңлаешлы, үтемле һәм объектив формада җиткергәннәре өчен, шулай ук ике дәүләт телен тигез күләмдә өйрәнү һәм файдалану мәсьәләсен күтәреп чыгып, ата-аналарның игътибарын шушы проблемаларга җәлеп иткән өчен, каләм ияләренә үзенең олы рәхмәтен җиткерде.

## Өйләнәсең килсә...

Казанның Галиев мәчетендә мөселман яшьләренең чираттагы дискуссион клуб утырышында төрле диндәге милләт вәкилләренең никах укып гаилә кору мәсьәләсе каралды. Әбу Яхъя хәзрәт никахның шартларын, таләпләрен аңлатты, Коръәни-Кәримдә һәм хәдисләрдә нинди диндәге кешеләргә никахланырга рөхсәт ителүе, ә кемнәр белән гаилә корырга ярамавын җиткерде, катнаш милләт никахларын бәяләү буенча зур тәҗрибәле кешеләргә, казыйларга, аксакалларга мөрәҗәгать итәргә кирәклеген әйтте.

## Бергәләп – шугалакка!



Чаллының “Нур-Ихлас” мәчете яшь мөгаллимнәре якшәмбе дәресләренә йөрүче балалар өчен күңелле чараларны еш үткәрә. Күптән түгел, “Виктория” балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе директоры Әлфәрит Раиф улы Нәбиев ярдәме белән, “Медео” шугалагында күмәк шуу оештырдылар. Күңелле шуудан соң балалар ачык һавада бергәләшеп чәй эчтеләр. Мондый актив ялдан һәркем бик канәгать калды.

# ИМАН КӘЛИМӘСЕ

*Барча галәмне юктан бар кылучы, Раббыбыз Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләгә хәмдесәнә, мактауларыбыз, сөекле пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә күңелебезнең түреннән чыккан салават-шәрифләребез булса иде һәм дә аның әһле бәйтенә сәламнәребез ирешсә иде. Әссәламүгаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ. Һәрберебезгә дә Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгаләнең сәламе, ике дөнья рәхмәте һәм бәракәте булсын!*

*Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә "Кыйтал" ("Мөхәммәд") сүрәсенең 19 нчы аятендә: "Бел: һич Илаһә юктыр, мәгәр Аллаһ Үзе генәдер...", - ди. Без, мөэмин-мөселманнар, Әбү Хәнифә мәзхәбе буенча Ислам динен тотучылар, "Ләә иләһә иллаллаһ" дип иман кәлимәсен тел белән әйтеп, күңел белән ышанып иман китердек. Көненә 5 вакыт намаз укыган саен 17 тапкыр укыйбыз, ә һәрбер намазга мөәззин азан әйткәндә, 15 тапкыр аңа ияреп кабатлыйбыз, камәттә 15 тапкыр тыңлыйбыз. Әйткән һәрбер сүзебезнең мәгънәсен аңлаган кебек, ошбу кәлимәнең дә мәгънәсен аңларга тиешбез. Әгәр дә мәгънәсен аңламасаң, күңел белән ничек кабул итә алырбыз? Ә бит Аллаһ безгә "иман кәлимәсенең мәгънәсен бел" дип боерган.*

Бик кызганыч, әлбәттә: бүген күпчелек әбибабайлар да үзләренең оныкларына "Ләә иләһә иллаллаһ" кәлимәсен аларны кияүгә биргәндә, яисә өйләндергәндә генә, имам килер алдыннан, дәфтәр битенә язып өйрәтеп маташалар. Ул балаларның күбесе тәрҗемәсен һәм мәгънәсен белми дә, аңламый да. Чөнки аны өйрәтүче еш кына ул кәлимәнең нәрсә аңлатканын үзе дә төшенми. Никах укырга баргач, өйләнешүчеләрнең "Ләә иләәһә иллаллаах" кәлимәсен ватып-сындырып «әйткәннәрен» күп мәртәбә күрергә һәм ишетергә туры килде. Шәһәдәт кәлимәсен әйтергә сорасаң, нишләпләр сорадым икән дип, эчтән генә "СөбханАллаһ" дип, үкенеп куясың. "Хәзрәт, яшьләргә ничек дөрес әйтергә икәнен өйрәт әле", — диләр. Ә бит ошбу кәлимәне никах укырга килгән имам түгел, ә әти-әни өйрәтергә тиеш. Бервакыт, кызына никах укытырга дип чакырырга килгән ханымга: "Яшьләр иман кәлимәсен дөрес итеп әйтергә өйрәнсеннәр", — дигәч, "Ничек инде хәзер яшьләрдән андый сүзне әйттереп булсын", — дигән сүзне ишетергә туры килде. "Өйрәткәндә ялгышмас өчен, башта үзегез дөрес әйтеп, мәгънәсен өйрәнегез", — дигәч, "Без мәчеткә килеп имтихан бирергә тиешме?" — дип куйды. Кәлимәнең мәгънәсе — "Аллаһтан башка гыйбадәт кылынырга тиешле бернинди илаһлар (затлар) юк" икәнен һәрбер мөселман белергә бурычлы. "Ләә иләәһә иллаллаһ" кәлимәсеннән чыккан мәгънәләргә шикләнергә ярамый. "Хуҗура" ("Бүлмәләр") сүрәсе, 15 аять: "Бары мөэминнәр, шундый адәмнәр ки, Аллаһка һәм Аның расүленә иман китерделәр, моннан соң иманнарында һич шик кылмадылар" (49/15).

Китергән иманнарына шикләнмәгән кеше генә хак мөселман булуын Раббыбыз ачык итеп әйткән. XX гасырның 17 нче елында булып үткән революциядән соң, имансызлар Дарвинның "кеше маймылдан барлыкка килгән" дигән, үз акылында булган кешенең башына да сыймаслык сүзләрен милләтебезгә килеп сөйли торгач, бик күпләр шикләнеп, Коръән китапларын ераграк яшереп куйдылар, Марксның "үләсең дә бетәсең" дигән сүзенә ышанып, намазларын да ташладылар. Ә кайберләре ялганны чынбарлык дип кабул итеп, динне искелек калдыгы дип, мәчетләрне яптырып, үзләренең остазлары булган имамнарны сөргенгә сөрделәр. Диненнән бизгән татар халкы башта бер-берсеннән яшергән булып, аз-азлап аракы эчә башлады, ә инде Бөек Ватан сугышыннан соң бергәләп җыелып, чиләкләп эчәргә тотынды. Дуңгызны асрау гына түгел, хәтта дуңгыз итенә якын килергә җирәнгән татар халкы, "үзебез итен ашамыйбыз" дигән сылтау белән, дуңгыз асрый башлады. Эчкән аракысы, кылган зинасы, асраган дуңгыздан булган табышы белән мактана башлады. Моның нәтиҗәсе буларак, милләтебез иманына шикләнгәнгә күрә, милләтебездән бәрәкәт китте, милләтебез бүгенге көндә бер аягы белән упкын өстендә. Тагын азгынлык кылуын дәвам итсә, упкынга төшеп китәчәк.

"Ләә иләһә иллаллаһ" кәлимәсен ялганламыйча әйтергә кирәк. Кешеләр янында кәлимәне ихластан әйтәме, юкмы — без белмибез. Әйтүченең ихласлыгы ни дәрәҗәдә икәнен Аллаһы Тәгалә белә. Алар турында Коръәни Кәримдә "Бәкара" сүрәсенең 8,9,10 аятьләрендә: "Мөселманнар арасында монафикъләр да бар, алар үзләре Аллаһка һәм ахирәт көненә ышандык диләр, ышанмасалар да (8). Ул монафикъләр Аллаһны һәм мөселманнарны алдамакчы булалар, ләкин һич алдый алмаслар, сизмичә фәкать үзләрен генә алдыйлар (9). Аларның күңелләрендә Аллаһка каршылык чире бар, Аллаһ аларның каршылык чирләрен арттырды, вә аларга ялган сөйләгәннәре өчен ахирәттә газаб тиеш (10)", — ди.

"Ләә иләәһә иллаллаһ" кәлимәсен кабул иткәч, без Раббыбыз Аллаһка буйсынырга тиеш булабыз. "Зүмәра" сүрәсе ("Халык төркеме") 54 нче аятьтә: "һәм Аллаһка буйсынучан булыгыз һәм газаб килмәс борын Аллаһка гыйбадәт кылыгыз, вә Аңа итагать итегез, газаб килсә, сезгә ярдәм бирелмәс бит", — диелә.

Кайберәүләр: "Мин Аллаһы Тәгаләне яратам, Аның бар икәнен дә беләм, җәннәт белән җәһәннәмнең бар икәнен, Ахирәткә дә ышанам, мөселман кеше намаз укырга, ураза тотарга тиеш икәнен дә, әйтмәсәләр дә беләм. Әмма намаз укырга вакытым да, теләк тә юк хәзергә, ураза тотам дип, көне буе ашамыйча йөри алмыйм бит инде", — диләр. Ә үзләре Аллаһ әйткәннәргә буйсынам, диләр. Бу нинди буйсыну була инде? "Ләә иләәһә иллаллаһ" кәлимәсен әйткәндә ихласлык та сорала. Кайбер кешеләр Аллаһы Тәгаләгә һәм Аның белән беррәттән икенче бер илаһка да ышаналар. Мисал өчен: яһүдиләр Гозәер галәйһиссәләмне һәм насаралар Гайсә галәйһиссәләмне Аллаһ улы дип саныйлар, ә аның анасы Мәрьямне илаһе дип атыйлар. Икенче берәүләр "Кыш бабай" дигән поттан бәхет сорыйлар.

Ә бит "Бәйинә" сүрәсе, 5 аятьтә: "Китап белән гамәл кылмыйча, кәфер булган яһүдләр һәм насаралар Аллаһ тарафыннан боерылдылар Аллаһ ризалыгы өчен генә Ислам динен тотарга, Аллаһка гына гыйбадәт кылырга", — диелә.

Арабызда күп кешеләр намазларын да укыйлар, уразаларын да тоталар, зәкәт сәдакаларын да бирәләр, хаҗ да кылалар, әмма Аллаһы Тәгаләнең кайбер аятьләрен кабул итмиләр. Шуның белән иманнарыннан колак кагалар. "Ниса" сүрәсе 3 аять: "Никахланыгыз үзегезгә хуш килгән ятимнәргә (хатыннарга), икегә, өчкә, дүрткә", — диелә. Әмма кайбер мөселман хатын-кызлары ошбу аятьне кабул итәселәре килми. Аллаһы Тәгалә үзе мөселман ирләренә бер үк вакытта дүрт хатынга өйләнергә рөхсәт итә.

Ә "Нур" сүрәсенең 31 аятендә мөслимә хатынкызга кушып әйтелә: "...Башларын, муеннарын вә күкрәкләрен пәрдәләр белән капласыннар, вә зиннәтләрен ачмасыннар". Аллаһ мөселман булган хатын-кызларны чәчләрен, муеннарын, беләкләрен, тубыкларын, балтырларын, колак алкаларын, муенга таккан зиннәтләрен һәм беләзекләрен ят ирләргә күрсәтүдән тыйды. Берәүләре үзләренең наданлыклары аркасында гаурәт җирләрен күрсәтеп йөрсә, икенчеләре хәтта телевизордан ничек итеп хатын-кызлар үзләренең зиннәтләрен күрсәтеп йөрергә тиешлеген өйрәтәләр.

Кем Аллаһы Тәгаләне яратмый, аның динен дә яратмый. "Аллаһтан башка гыйбадәт кылынырга тиешле бернинди илаһлар (затлар) юк" дигән мәгънәгә ия "Ләә иләәһә иллаллаһ" кәлимәсен дә ихластан, шикләнмичә, ялганламыйча, буйсынмыйча, кабул итмичә әйтеп, бернинди мәгънә дә юк. Кәлимәдән чыккан шартларны тулысынча кабул иткән кеше генә Ислам диненә тугры була. Иманына тугры булган кеше намазны да тәмен табып укый, уразаны да ләззәтләнеп тота, зәкәтне бирсә дә күңеле тынычлана. Ә инде туган теле, милләте бетүгә барса, Ислам дине зәгыйфьләнсә — борчыла.

Гата бине Әбү Рүбәхәдән риваять ителде, ул әйтте: "Мөэминнәрнең гөнаһларын Ярлыкаучыдыр һәм тәүбәләрен кабул итүче, имансызларны каты газап итүчедер" (Гафир — Мөэмин:3) дигән аятьнең тәфсире турында Ибн Габбастан сорадым. Ибн Габбас әйтте: "Ләә иләәһә иллаллаһ" дип әйткән кешенең гөнаһысын ярлыкаучы. "Ләә иләһә иллаллаһ" дип әйткән кешенең тәүбәсен кабул итүче. "Ләә иләһә иллаллаһ" дип әйтмәгән кешене каты газап кылучыдыр". (40/3)

Әнәс бине Мәликтән риваять ителде, Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнән: "Әй Рәсүлуллаһ, җәннәт өчен акча бармы?" — дип сорадылар. Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: "Әйе, аның акчасы — Ләә иләһә иллаллаһ сүзедер".

Әбү Һөрәйрадан риваять ителде, ул әйтте: "Әй рәсүлуллаһ, иң алдан адәмнәрдән синең шәфәгатеңә кем лаек?" Ул әйтте: "Чын күңелдән "Ләә иләһә иллаллаһ" дип әйткән кеше минем шәфәгатемә лаек".

Мөселман кардәшләрем, "Ләә иләһә иллаллаһ" дип әйткән кешенең җәзасы җәннәт кенәдер" икәнен онытмаска иде. Барчабызга да иман байлыгы, гаилә бәхете, күңел тынычлыгы, үзебезгә, нәселебезгә, туган телебез — татар телендә сөйләшеп, аралашып яшәргә Раббыбыз насыйп итсә иде.

**Равил хәзрәт Нуруллин,**
**"Туфан" мәчете имам-хатыйбы.**

## Беләсезме?

*Коръән Кәримдә Адәм галәйһи вә сәлләмнән башлап Мөхәммәдкә (с.г.в.) кадәр килеп җиткән пәйгамбәрләрнең төгәл саны күрсәтелми, әмма хәдисләрдәге мәгълүматка таянып, кайбер галимнәр кешеләргә барлыгы 124 меңләп пәйгамбәр җибәрелгән дип әйтә. Ләкин аларның төгәл саны Аллаһы Тәгаләгә генә мәгълүм.*

*Коръәндә 25 пәйгамбәрнең исеме искә алына: Адәм, Нух, Идрис, Ибраһим, Исмәгыйль, Юныс, Муса, Давыт, Зәкәрия, Исхак, Сөләйман, Һуд, Салих, Ягъкуб, Йосыф, Лут, Шөгәеб, Ильяс, Яхья, Әюб, Зөл-Кифел, Һарун, Әл-Йәсәгъ, Гайсә, Мөхәммәд – Аллаһы Тәгалә алардан разый булсын.*

## СОРАУ-ҖАВАП

*Сорауларга шәригать белгече **Рәфыйк** хәзрәт **Миннәхмәтов** җавап бирә*

**Мөхтәрәм “Ислам нуры” редакциясе!**

**Түбәндәге сорауларга җавап бирсәгез иде.**

**Акча тапсаң, аны иясенә тапшырырга диелә. Гадәттә аның иясен табу булмый торган хәл. Мәсәлән, аны мәчеткә тапшырсаң да гөнаһ булмый дип уйлыйм, ә минә вак акчаны күп кеше алмый. Бу дөресме, исраф түгелме?**

**Өйлә намазы зәвалдән соң, өйлә вакыты кергәнче уку дөресме?**

**Сезгә уңышлар теләп,**

**Салих Зиннәтов,**
**Зәй районы, Аксар авылы**

**Җавап:** Югала яки бозыла торган әйбер тапсаң, аны алу вәҗиб, ягъни тиеш санала. Акча да, алтын-көмеш тә вәҗибкә керә, чөнки, әйтик, җиргә төшсә, алар югалырга мөмкин. Алган кеше үзе мохтаҗ, хәерче икән, тапкан әйберне куллана ала. Мохтаҗ түгел икән, өч көн игълан итеп, хуҗасын көтә. Хуҗасы табылса, түләргә тиеш була. Зур, кыйммәтле әйбер табылган очракта, аны бер ел дәвамында саклау тиеш. Бер елдан соң да иясе табылмаса, үзе фәкыйрь булса – табылдыкны куллана, мохтаҗлыгы булмаса – сәдака итеп бирә. Бер ел узып, инде сәдака итеп бирелгәннән соң хуҗасы табыла калса, ул югалган малын кире кайтаруны таләп итмәсә, сәдакадан китсен, дисә, бирелгән сәдака аның исеменнән китә. Әгәр хуҗа, малының сәдака буларак китүенә риза түгел икән, бу очракта малны тапкан кеше хуҗага түләргә тиеш була, ә сәдака аның үз исеменнән китә.

Вак акча табылса да, аны алу яхшырак. Югалткан кеше мохтаҗрак заттан булса, эзләп тә килә әле аны. Хуҗасы табылса, бер суммы, биш суммы – кайтарып бирергә кирәк. Дөрес, гомуми урыннарда, мәсәлән, вокзал кебек җирләрдә, еш кына аның хуҗасын табу мөмкин булмый.

Өйлә вакыты кергәнче укылган намаз өйлә булмый, нәфел намазы була. Вакыты кергәч, өйлә намазын кире укырга кирәк.

**Без шәһәр фатирында яшибез. Кечкенә чактан ук песи алып кайтырга тели идем. Тик әти-әнием рөхсәт итми, өйдә песи тотарга ярамый, диләр. Бу чыннан да шулаймы?**

**Адилә Галиева, Чаллы кызы.**

**Җавап:** Песине авылда да, шәһәрдә дә өйдә асрарга ярый, ул йорт хайваны санала. Этне генә өйдә тотарга ярамый.

**Машинаны сатарга теләгән идем, белдерү буенча еш кына алыпсатарлар – перекупщиклар килеп җитә. Юк гаебен дә тапкан булып, алдап-йолдап, бу җире ватык, бу җире болай дип, ничек тә мин сораган бәяне төшерттерергә телиләр. Аларның болай эшләве гөнаһтыр бит инде...**

**Наил Ф., Алабуга шәһәре.**

**Җавап:** Сәүдәдә, сатып-алу белән шөгыльләнүдә гөнаһ юк, ләкин алганда да, сатканда да алдарга ярамый. Товарының нинди дә булса кимчелеге бар икән – сатучы аны әйтергә, күрсәтергә тиеш. Алучы юк кимчелекләрне бар дип исбатларга маташса, гөнаһы үзенә була. Машина сатучыга килгәндә, товар синеке бит, теләсәң – бу кешегә сатасың, теләмәсәң – юк, анысы үз ихтыярында. Үз бәяңне куеп сатасың, чөнки товарның хуҗасы син.

*Юл язмасы*

# “Уеңны да ишетүче бар...”

*Диләрә апа шулкадәр ачык йөзле, кунакчыл ханым, елмаеп кына сөйләгән һәр сүзе — үзе бер хикәят. Сөйләгән арада, хикәятенә бәйле рәвештә, кишер үстергән бакчасын да, су баскан базын да, хаҗ сәфәреннән алып кайткан күлмәкләрен дә күрсәтергә өлгерде.*

- Кияүгә динле кешегә чыктым мин, ирем бик акыллы, ипле кеше булды. Барысын да сабыр гына аңлата торгач, мин дә әкренләп акны карадан аера башладым, догалар өйрәндем, намазга бастым. Баштагы елларны барыбер эчемдә ниндидер кирелек булган инде дим... Кечерәк кенә бакча алган идек, язын әй сөенә-сөенә түтәлләр ясадым, кишерен-чөгендерен утырттым. Үзем кишер утыртам, үзем Аллаһы Тәгаләгә ялварам: “Уңышларын мул кылсаң иде, күзен гошерен дә бирерлек булса иде”, — дип теләкләр телим. Күзен күрсәң, күзләреңә ышанмас идең: ашъяулык хәтле түтәлләрдән йодрык-йодрык чөгендер, таза-таза кишер җыеп алдым бит! Шулчак эчкә корт керде: моннан кемгәдер гошер илтеп бирсәң, кыш үтүгә, үзеңә барыбер кибеттән сатып аласы булачак инде, бер елга җитәрлек түгел дә түгел... Шулай дип уйландым да, яшелчәләремне бик әйбәтләп җыеп, чистартып, өй базына керттем дә салдым.

Безнең монда, үз йортыбыз булгач, газы да, суы да үзебездә дигәндәй... Көзге көннәрнең берсендә ирем берничә көнгә Казанга китеп барды, мин өйдә калдым. Беркөнне краннны ачам — су беткән. Исем китмәде, андый хәл булыштыра бит инде, ишегалдындагы колонкабыздан алып кердем. Су икенче көнне дә юк, өченче көнне дә. Болай озакка киткәне юк иде, аптырап, су насосын карыйм әле дип, баз капкачын ачсам... Ике метр тирәнлектәге баз су белән мөлдерәп тулган, идән тактасына тияргә ике бармак буе калгандыр. Кишер-чөгендерне әйтәсеңме? Менә шул базда инде, шунда. Суы бер хәл, мин анда кумак-тычканга агу куйган идем бит, шул суга таралып беткән... Шулай итеп, ул елны үзем үстергән бер генә яшелчәне дә авыз итү мөмкин булмады. Гошер бирергә дигән ниятемне үзем үк күпсенгәч ни...

Ирем без өйләнешкәнче үк хаҗда булып кайткан иде, бер елны әйтә бу: “Быел сине дә алып барам, Алла боерса”, — ди. Мин тешем-тырнагым белән каршы төштем, ни өчен дисәң, шул елны гына машина алган идек, туганнарыбызга сиксән мең бурычыбыз бар. Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә диләр, муеннан бурычың булсын, ә син ике кеше хаҗга барырлык акча турында хыяллан... Ирем әйтә: “Ә син биш вакыт намаз укыган саен, дога кылып, Аллаһы Тәгаләдән сора, ул ишетүче, ул кабул кылучы”, — ди. Шуннан ул әйткәнчә, һәр намаз саен шулай дип теләк тели башладым, хәерле гамәлләр, хәләл маллар сорап дога кылдым. Мин массажистка булып эшли идем, шул чорда заказ өстенә заказ китте, иртәдән-кичкә кадәр берсеннән-икенчесенә йөгерәм; иремнең дә бер минут эшсез торганы юк, сәүдәсе гөрләп бара... Кыска гына вакыт эчендә теге сиксән мең бурычны түләп бетердек; күз башында инде хаҗга барырлык сумма да тупланган иде. Мин дә “йомшарып” киттем, аруымны, вакыт юклыкны үземә сәбәп итеп, намазымны ашыгып кына укый башладым, дога кылып, теләк теләп утырырга, әлеге дә баягы вакыт юк... Беркөнне бер пациентыма массаж ясарга барам, өченчеме, дүртенчеме көне иде, бу ханым әйтә: “Иртәгә Оренбургка китеп барам, массажны туктатырга туры килә инде”, — ди. “Ярар, — дим, күңелемнән генә, — әле башка пациентларым күп бит”, — дим. Икенчесенә барсам, анысы: “Биш көн массаж алгач, кулбашларым язылды, рәхмәт яусын, әлегә җитеп торыр”, — ди. Өченчесенең баласы авырып киткән, үзе турында кайгыртырга җае юк... Шулай итеп, бармак арасыннан коелган ком шикелле, пациентларым берәм-берәм коела башлады бит, яңалар да күренми.

Бар нигъмәтнең, бар хикмәтнең иясе Аллаһы Тәгалә икәнен онытып, тәкәбберләнеп китсәң, тагын нәрсә көтмәк кирәк?..

Ул елны ирем тәки хаҗга алып барды бит! Гыйбрәтләр алып, исән-сау әйләнеп кайттык, Аллага шөкер. Хаҗ кылу, андагы тәэсирләр — сүзгә генә сыя торган түгел, олы бер хикмәт икән!

Монысын сүз уңаеннан гына сөйлим: кибетләргә йөрергә чыккач, күчтәнәчләр-бүләкләр алдык. Мин шул сумкамны күтәреп, тагын бер кибеткә кердем. Бер күлмәккә күзем төште дә, шуны киеп карыйм дип, сумкамны кәнәфигә куеп, эчкә кереп киттем. Күлмәкне салып, башкасын кидем, ошатканын алып, акча түләп чыгып киттем. Ярты дөньяны әйләнеп, бик соңлап кына кунакханәгә кайттып кердек. Бераздан ирем белән бер-беребезгә карашабыз: бүләкләр салынган сумканы кайдадыр калдырганбыз лабаса! Башны эшләтә торгач, мин күлмәк киеп караган кибеттә калуын аңладык аңлавын. Төн уртасында чыгып китеп булмый бит, безгә язган булса, табылыр, иншалла, дидек тә ятып йокладык. Икенче көнне тагын шул маршрут буенча чыгып киттек, әле иң башта ул кибетнең кайда икәнен табарга кирәк. Йөри торгач, таптык барыбер. Кибетче егеткә нәрсә кирәген вата-җимерә тел белән дә, кул ишарәләре белән дә аңлаткач, эчкә үтсәк, безнең сумка кичә мин ничек калдырсам шул рәвешле кәнәфидә ята! Бездән битәр, кибетче егетнең сөенүен күрсәгез сез! Соңыннан белдек: сумканың хуҗасы табылганчы алар үзләрен шушы әйбер өчен җаваплы хис итеп, гөнаһлы санап, югалткан кешедән битәр җан ата икән! Әйтәм аны ул чагында әлеге карачутыр егет май кояшы кебек елмаеп, безгә бүләкләр бирә-бирә, шултиклем куанып озатты үзебезне...

Иман нуры булган илдә яшәү рәвешенең ничек икәнен шушы гади генә мисалдан да чамаларга була...

**Айгөл Әхмәтгалиева.**

*Безгә язалар*

Әссәламугаләйкум, “Ислам нуры” хезмәткәрләре! Мин сезнең барыгызга да уңышлар, сәламәтлек, дөнья-ахирәт бәхете телим. Газетаның һәр санын яратып укыйм, бик ихтирам итәм. Үзем дә сезнең игътибарга шигъри язма җибәрәм әле.

**Олы галимебез Шиһабетдин хәзрәт истәлегенә**

Анасыннан биш яшендә
Ятим калган Шиһаб Мәрҗани.
Шуңа күрә ана назын
Күрәлми шул әллә ни.
Мәгърифәтле ата-анадан
Тугангамы, китап ярата.
Укып, рухи көч туплый,
Кайгы-хәсрәтен дә тарата.
Авыл урамында йөргән чакта,
Дус-ишләрен күреп сөенә.
Сабан туйларында батыр кала,
Көчсезләре аннан чигенә.
Гомер уза, үсмер егет
Сәүдәгәргә утырып юлга чыга,
Бохарага гыйлем алырга.
Тәвәккәллек, мөстәкыйльлек җитә —
Нигә әле нәүмиз калырга?
Тырыша торгач, ныклы гыйлем туплап,
Бохараны, Сәмәркандны урап,
Олы галим — Шиһабетдин Мәрҗани
Туган якка кайта, халкын зурлап.
Дөрес юл күрсәтеп халкына,
Күпме китап, язу калдыра.
Шиһабетдин Мәрҗани
Күңелләрдә учак яндыра,
Тик иманлы булып кал гына.
Гасырлар үтсә дә онытылмый
Олы галимнәрнең хезмәте.
Халкы аңа бүген рәхмәт укый —
Хезмәтенә күрә — хөрмәте!

**Тәзкирә Алякимова,**
**Нурлат районы, Түбән Норлат авылы.**

*Гамьле әңгәмә*

# Таныштыра, кавыштыра “Мәрхәмәтле ярдәм”

***Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә: “Мин сезне ир һәм хатын буларак парлы итеп яралттым. Мин сез күргән һәм күрмәгән әйберләрне дә парлы итеп яралттым”, — ди.***

Һичшиксез, һәр адәм баласы киләчәге ышанычлы, рухы сәламәт, үзара әдәпле, итагатьле мөнәсәбәтләр булган гаилә төзергә тели. Әгәр туган-тумача, дуслар-танышлар арасында насыйп ярың табылмаса, нишләргә соң? Бу очракта ярдәмгә танышу үзәкләре килә.

Чаллыда, күпме генә сорашсам да, миңа шундыйрак үзәк булуын әйтүче кеше очрамаган иде. Әйе, әледән-әле интернет-сайтлар да ачыла бугай. Кызыксынып китеп, шундыйларның берсенә кереп чыкканым да булды. Әмма биредә “уйнап йөрү” яхшы гамәл түгеллеген белгәнгә, бер көнлек аралашу белән чикләнергә туры килде.

Бу тема белән кызыксынуымны оныта да башлаган идем инде, “Хәләл-Үзәк” сәүдә йортында мөселманнар өчен “Мәрхәмәтле ярдәм” таныштыру үзәге ачылуы турында белеп алдым. Әлбәттә инде, әле эшен башлап кына җибәрүче бу үзәк белән танышып чыкмау — дөрес булмас дигән уйга килдем. Әңгәмәдәшем- агентлыкның администраторы Эльвира Сабитова.

**- Эльвира ханым, мөселманнарны үзара таныштыруга ихтыяҗ бармы шәһәрдә?**

- Мөселманнарга хәләл җефетләрен табу бүгенге көндә Чаллыда да, башка шәһәрләрдә дә шактый авыр, чөнки алар яшәгән яки эшләгән мохиттә үзләренә тиң булырдай кеше юк дәрәҗәсендә. Ихластан Аллаһыга ышанган мөселман кешесе тыйганнан тыелып яшәргә омтыла, дөньяви җәмгыятьтә кабул ителгән кайбер яшәеш тәртипләрен кабул итми. “Мәрхәмәтле ярдәм” таныштыру үзәген ачу идеясе ул нәкъ менә шундый ихтыяҗны истә тотып барлыкка килде дә инде. Гомумән, бу үзәкне ачу — ул “Мәрхәмәтле ярдәм” проектының бер юнәлеше генә, аның күп төрле юнәлешләре бар. Хәйриячелек, мәсәлән.

**- Таныштыру эше ни рәвешле оештырыла сездә?**

- Безгә мөрәҗәгать иткән егет-кызлар, апа-абыйлар башта анкета тутыралар, без, әлбәттә, аларның паспорт күчермәләрен, фотоларын алабыз. Болар безнең өчен генә, кешегә күрсәтелми. Шуннан соң әңгәмә корабыз. Анкетада кеше тулаем ачылып бетмәскә мөмкин, үзара сөйләшү ул бүтәнрәк. Аралашкан чакта аның уй-фикерләре, теләк-омтылышлары, тормышка карашы яхшырак күренә. Ныклы гаилә корыр өчен, төрле параметрларның туры килүе мөһим, без шуларны исәпкә алырга тырышабыз. Анкеталарын өйрәнгәннән соң, үзара тәңгәл килергә мөмкин потенциаль парларны вәлиләр катнашында очрашуга чакырабыз. Алар әти-әниләре, абый-апалары, дуслары, опекуннары белән килергә мөмкин. Дустанә әңгәмә барышында, чәй өстәле артында алар бер-берсен күрә, сыный. Парлар олырак булган очракта балаларының фикерләрен тыңлыйбыз. Бу эшнең үз нечкәлекләре, һәр парга карата шәхсән якын килү сорала. Таныштыру белән генә эш бетми. Даими рәвештә хатын-кызлар һәм ир-егетләр өчен “Гаилә нигезләре”, “Әдәп” һ.б. темаларга укулар үткәрелә. Безнең үзәк шәригатькә һәм Россия кануннарына нигезләнеп эшли. Соңгысына туктапганда, бу безгә мөрәҗәгать итүчеләргә 18 яшь тулган булырга тиеш дигән сүз, мәгълүматларның конфиденциальлегенә дә җитди игътибар бирелә.

**- Мин сезнең турыда очраклы рәвештә генә белеп алдым. Ә сезнең хезмәтләргә мохтаҗ кешеләр ничек таба ала сезне?**




- Чаллы шәһәрендә “Мәрхәмәтле ярдәм” таныштыру үзәге ачылу турындагы хәбәр мөселманнар арасында иң элек “сарафан радиосы” аша таралды. Мөселман даирәсе үзара тыгыз аралаша, барысы өчен дә күркәм яңалык булган бу хезмәт тиз арада барлык ялгызакларга да барып ирешер, иншаалла. Социаль челтәрләрдә үз сәхифәләребезне ачып җибәрдек, анысы читтә яшәүчеләрне дә таныштыру мөмкинлеге булсын өчен кирәк.

**- Димәк, әгәр мин Татарстанның ерак бер авылында, яки, гомумән, Татарстаннан да читтә яшәүче ялгыз хатын яки ир-ат булсам да, сезнең үзәк аша үз парымны таба алачакмын?**

- Әлбәттә. Бу очракта анкетаны, паспорт күчермәсен һәм фотоны почта аша җибәрергә була. Анкетаны кулдан тутырып, имзалап, скрин белән җибәрүне сорыйбыз, чөнки бу хокукый яктан дөресрәк дип саныйбыз. Шулай да барыбер аларны бирегә чакырабыз, җайлары булганда киләләр. Анкета үрнәген сайтта урнаштырырга җыенабыз. Эшебез әле башланып кына килә, шунлыктан сайтны да тиешле дәрәҗәгә җиткереп бетерәсе бар әле. Татарстан районнары белән, әлбәттә, сайт аша гына эшләүне күздә тотмыйбыз. Тора-бара ялгызакларны барлау, таныштыру эшенең башка ысулларын да гамәлгә кертербез дип уйлыйбыз. Төрле сәбәпләр аркасында ялгыз калган, менә дигән әти яки әни булырлык, үрнәк ир яки хатын булырлык мөселманнарны таныштыру — безнең саваплы гамәлебез булыр дип ышанабыз.

- Сез бары тик ислам кануннары белән яшәүче парсызлар белән генә эшлисезме? Яшерен-батырын түгел, үзен мөселман татары дип санаучы, ләкин гамәлләрен тиешенчә үтәмәүче кешеләр шәригать кануннары буенча яшәүчеләргә караганда күбрәк тә бит.

- Без андый катгый таләпне куярга тырышмыйбыз. Әлбәттә, гаилә дәвамлы булсын өчен, динебез ир белән хатынның биш төрле матдәдә —икесенең дә мөселман булуы, диннәренең торышы, мал, нәсел, һөнәр ягыннан якын булулары белән туры килүләрен шарт итеп куя. Шулай да әле иман, калебләре ныгымаган татарларыбыз белән дини юнәлештә дә эш алып барабыз. Күп кенә хаталар дини белемнең җитмәве белән дә эшләнелә.

- Соңгы соравым бу хезмәтнең хакы турында.

- Мөселманнарны таныштыру эшен без Аллаһ ризалыгы өчен түләүсез алып барабыз. “Һәрбер эш ниятkә карап бәяләнер” дигән хәдис тә бар. Һәркайсыбыз һәр эшебезне фәкать Аллаһ ризалыгын өмет итеп кенә эшләргә тиеш. Гаиләләргә тормыш корып җибәрүгә ярдәм — гамәл дәфтәренә язылаcы саваплы эшләрнең берсе дип инанып эшлибез бу эшне.

**Әңгәмәдәш – Лилия Фәттахова.**

*Бәйге! Бәйге! Бәйге!*

## “МИНЕМ ЮЛЫМ”



*Мөхтәрәм җәмәгать!*

*“Ислам нуры” газетасы битләрендә “Минем юлым” дигән ор-яңа бәйге игълан итәбез.*

*Һәркемнең тормышында гыйбрәтле, катлаулы мәлләр була. Сер түгел, кайберәүләр нәкъ менә авырлыклар белән сыналган вакытта Аллаһ җәбенә тотына, тормыш рәвешен тамырдан үзгәртә, ислам диненә якыная. Ә сезнең исламга килү юлы нидән гыйбарәт? – Шул хакта газетага хатлар юллагыз. Аларны кулдан язып, түбәндәге адреска җибәрергә мөмкин: 423802 Чаллы шәһәре, Үзәк урамы, 72 (ул. Центральная, 72), “Ислам нуры” газетасына. Конверт тышына “Конкурска” дип язарга да онытмагыз. Электрон хатлар булса, aygulli@mail.ru адресына җибәрә аласыз. Җиңүче дип табылган өч авторыбызны истәлекле бүләкләр көтә.*

*Бергә булыйк, аралашып яшик!*

Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР

Баш мөхәррир
Айгөл Абдуллина

Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

Оештыручылары:
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.

Электрон хатлар өчен:
e-mail: islamnury@mail.ru

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7–0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

Тиражы 1100.

Индексы 54149

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
423802, Яр Чаллы,
Үзәк урамы, 72

Басарга кул куелды:
график буенча
26 февраль 16 сәг.
фактта 26 февраль 16 сәг.

Бәясе ирекле